**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Зеленодольский муниципальный район
**Исполнительный комитет**
**Кугеевского сельского поселения**
ул. Мира, д. 22, с.Кугеево, 422516

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
Зеленодольск муниципаль районы
**Күгәй авыл җирлеге башкарма комитеты**

Тынычлык ур., 22 нче йорт, Күгәй авылы, 422516

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

2020 елның 19 феврале № 6

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, муниципаль хезмәтләр исемлеген актуальләштерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан бирелә торган беркетелгән муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга(кушымта 1).
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында " 2013 елның 12 августындагы 14 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. . Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтына урнаштырырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (администрация бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (мәдәният йорты бинасы).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Күгәй авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф. Х. Хисаметдинова

1 нче кушымта Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге башкарма комитеты карары буенча 2020 елның 19 феврале, № 6

**Татарстан Республикасы муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлеге**

| | *Муниципаль хезмәтләр* |
|---|---|
| 1. | Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару |
| 2. | Агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү |
| 3. | Документлар һәм аларның күчермәләре дөреслеген раслау |
| 4. | Нотариаль гамәлләр кылу: ышаныч таныклыгы |
| 5. | Белешмә (өземтәләр) |